СОВЕТ ЯМБУЛАТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯМБУЛАТ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**03.11.2015** **с.Ямбулатово** **№ 3 – 22**

Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлеге Уставының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында

«2016 елга Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары проектларын төзү һәм раслау үзенчәлекләре турында, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында» Федераль законның 3 статьясының үз көчен югалтуын тану хакында» 2015 елның 30 сентябрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлеге Уставы нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районының
Ямбулат авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлеге Уставының планлы чорга бюджет проектын төзү һәм раслау, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлеге Советына күрсәтелгән проект белән бер үк вакытта тапшыруга карата аерым нигезләмәләренең 2016 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдә булуын туктатып торырга(Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлегенең социаль-икътисадый үсеше фаразыннан, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлегенең бюджет сәясәтенең төп юнәлешләре, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлегенең салым сәясәтенең төп юнәлешләреннән тыш).
2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Ямбулат авыл җирлеге башлыгы М.Н.Ахметзянов